КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.12.2022 Казан шәһәре № 541-П

Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Сосновка авылы V» ачыкланган мәдәни (археологик) мәдәни мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, территория чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» 565 номерлы карары нигезендә боерам:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Сосновка авылы V» ачыкланган мәдәни (археологик) мәдәни мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Сосновка авылы V» ачыкланган мәдәни (археологик) мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
3. Бу боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Сосновка авылы V» ачыкланган мәдәни (археологик) мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга.
4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турындагы белешмәләрне Бердәм дәүләт күчемсез милек рееестрына кертүне тәэмин итәргә.
5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары М.М.Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2022
елның 14 декабрендәге 541-П
боерыгына 3 кушымта

Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районында урнашкан «Сосновка авылы V» ачыкланган мәдәни (археологик) мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану һәм башка эшләр буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Археологик мирас объекты чикләрендә урнашкан су объектын яисә аның өлешен кулланунның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның әлеге объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.